СОВЕТ КАМАЕВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНДЕЛЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КАМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423643 село Камаево, ул.Дифгата Сирая д.29А

423643 Камай авылы, Дифгать Сирай урамы 29А йорты

Тел.(885549)3-55-33 ИНН 1627001164, КПП162701001 ОГРН 1021601118043

Р Е Ш Е Н И Е К А Р А Р

2020 елның 7 нче декабреннән № 12

Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Камай авыл җирлегендә
муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә
үзгәрешләр кертү турында

2007 елның 2 мартындагы "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 25-ФЗ номерлы Федераль законы, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексы Менделеевск муниципаль районы «Камай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлеге Советының 2020 елның 23 апрелендәге 154 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Камай авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 11 статьясындагы 5 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, әлеге муниципаль хезмәткәр урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында, әлеге җирле үзидарәнең сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында күрсәтелгән вазыйфаны биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклый алмыйлар.»

1.2. 1 нче кушымтаның 13 статьясындагы 3 пунктының 4 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«4) хезмәт кенәгәсен һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр;»

2. Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм www.mendeleevsk.tatarstan.ru Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтының "Камай авыл җирлеге" бүлегендә урнаштырырга.

Менделеевск муниципаль районы
Камай авыл җирлеге Советы Рәисе И. И. Әһлиева